КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 35

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән расланган «Ел инженеры» республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел инженеры» республика конкурсын үткәрү турында» 2019 ел, 22 апрель, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 август, 642 нче; 2021 ел, 16 апрель, 254 нче; 2021 ел, 13 август, 717 нче; 2022 ел, 26 июль, 719 нчы; 2023 ел, 20 апрель, 508 нче; 2023 ел, 5 октябрь, 1235 нче; 2024 ел, 4 июль, 511 нче; 2025 ел, 2 июль, 481 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел инженеры» республика конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан М.М.Миңнуллинны, А.И.Поминовны, Р.Н.Садыйковны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Абашев Әлмир Рәшид улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын |
| Кадыйров Азат Рифгать улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын |

| | |
|---|---|
| Мөҗипов Рәмис Гаптрәис улын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасарын; |

Кирилл Германович Охоткинның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин